ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 июнь 2023 ел № 5185

Башкарма комитетның 2022 елның 9 декабрендәге 6986 номерлы карары белән расланган бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 9 декабрендәге 6986 номерлы карары белән расланган бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5.1 пунктта 3 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йорт – Россия Федерациясе Торак кодексының 36 статьясындагы 1 өлешнең 1-3 пунктларында күрсәтелгән мөлкәтне үз эченә алган, ике һәм аннан күбрәк фатирдан торган бина. Күпфатирлы йорт шулай ук үз эченә мондый күпфатирлы йортның аерылгысыз конструктив өлеше булып торган, аерым милекчеләргә караган торак булмаган биналарны һәм (яки) машина урыннарын алырга мөмкин;»;

2) 2.4.1 пунктта икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- бүлмәгә тикшерү үткәрмичә, гариза теркәлгән датадан башлап 30 календарь көн эчендә, ә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәнең (алга таба – 47 нче Нигезләмә) 42 пунктында каралган объектларның (торак урыннарның) гомуми исемлеге яки гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм шул ук вакытта

объектларның (торак урыннарның) гомуми исемлегенә кертелмәгән торак урын милекчесеннән, хокук иясеннән яки наемга алучыдан кергән гариза – теркәлгән датадан башлап 20 календарь көн эчендә һәм 47 нче Нигезләмәнең 47 пунктында күрсәтелгән карарны (бәяләмә рәвешендә) яисә бәяләнә торган бүлмәгә өстәмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итә;

- бүлмәгә өстәмә тикшерү үткәрелгән һәм бүлмәне тикшерү акты төзелгән очракта 45 календарь көн эчендә (административ регламентка 2 нче кушымта).»;

3) 2.5.1 пунктта:

- 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне раслаучы башка документ;»;

- 7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) торак урынның киртәләү һәм тотып торучы конструкцияләре элементларын тикшерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе – әгәр бәяләмә торак урынның 47 нче Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен (туры килмәвен) тану турында карар кабул итү өчен кирәк булса;»;

4) 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтләнгән экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.»;

5) 3.5.5 пунктта икенче абзацта «бүлмә тикшерелгән вакыттан башлап» сүзләрен «тикшерү датасы турында комиссия әгъзаларына, гариза бирүчегә һәм экспертларга хәбәр ителгән вакыттан башлап» сүзләренә алмаштырырга;

6) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.9 пункт өстәргә:

«3.9. Гомуми билгеләре буенча, шул исәптән аны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә мөнәсәбәтле рәвештә берләштерелгән гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә муниципаль хезмәт күрсәтү.

Муниципаль хезмәт гариза бирүченең категориясенә һәм мөрәҗәгатьнең нигезенә бәйсез рәвештә күрсәтелә.».

7) 2 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 16 июнендәге
5185 номерлы карарына
кушымта

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Бүлмәне (күпфатирлы йортны) тикшерү
Акты

№ ____________________ ___________________________________
(дата)

_______________________________________________________________________
(бүлмәнең (күпфатилы йортның) урнашу урыны, шул исәптән,
торак пункт һәм урам исеме, йорт һәм фатир номеры)

_______________________________________________________________________
(кем тарафыннан билгеләнгән, федераль башкарма хакимият органының,
Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органының,
җирле үзидарә органының исеме, комиссияне чакыру турында карар номеры)
билгеләнгән ведомствоара комиссия

рәис ___________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

комиссия әгъзалары _____________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
____________________________________________________________ составында
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

чакырылган экспертлар __________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм чакырылган торак милекчесе яки аның вәкаләтле заты ______________________
_______________________________________________________________________
___________________________________________________________ катнашында
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

___________________________________________________________________________

(гариза бирүченең реквизитлары: Ф.И.А.и. һәм адресы - физик зат өчен, оешманың исеме һәм биләгән вазыйфасы - юридик зат өчен)

гаризасы буенча түбәндәге бүлмәгә (күпфатирлы йортка) тикшерү үткәрде һәм әлеге бүлмәне (күпфатирлы йортны) тикшерү акты төзеде:

___________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________.

(бүлмәнең адресы, кемнеке булуы, кадастр номеры, файдалануга тапшыру елы)

Торак урынның, бинаның тотып торучы конструкцияләре, инженерлык системалары, җиһазлар һәм механизмнарның һәм бина янындагы территориянең торышына кыскача тасвирлама

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________.

Билгеләнгән таләпләргә туры килмәү турында мәгълүматлар, күрсәткечнең фактагы зурлыклары яки конкрет туры килмәүнең тасвирламасы белән

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________.

Үткәрелгән инструменталь контроль һәм тикшеренүләрнең башка төрләре нәтиҗәләрен бәяләү ______________________________________________________

__________________________________________________________________________.

(контроль (сынау) кем тарафыннан үткәрелгән, нинди күрсәткечләр буенча, фактагы нинди зурлыклар алынган)

Ведомствоара комиссия рекомендацияләре һәм даими яшәү өчен куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм нормаль шартлар тудыру өчен кабул ителергә тиешле тәкъдим ителә торган чаралар _____________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________.

Бүлмәне тикшерү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия бәяләмәсе

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________.

Актка кушымта:
а) инструменталь контроль нәтиҗәләре;
б) лаборатор сынаулар нәтиҗәләре;
в) тикшеренүләр нәтиҗәләре;
г) махсуслаштырылган оешмалар экспертларының бәяләмәләре;
д) ведомствоара комиссия карарлары буенча башка материаллар.

Ведомствоара комиссия рәисе

____________________________________________________________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Ведомствоара комиссия әгъзалары

| | |
|---|---|
| (имза) | (Ф.И.А.и.) |
| (имза) | (Ф.И.А.и.) |
| (имза) | (Ф.И.А.и.) |
| (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева